Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советының кырык тугызынчы утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

5 декабрь, 2024 ел № 369

«2020 - 2024 елларга Питрәч муниципаль районы яшьләрен патриотик тәрбияләү» район программасын гамәлгә ашыру турында хисап хакында

Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары «2020 - 2024 елларга Питрәч муниципаль районы яшьләрен патриотик тәрбияләү» район программасын гамәлгә ашыру турындагы хисап хакында мәгълүматны тыңлап **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. «2020 - 2024 елларга Питрәч муниципаль районы яшьләрен патриотик тәрбияләү» район программасын (алга таба - Программа) гамәлгә ашыру турында хисап хакында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

2.1. түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- 2025 - 2028 елларга планлаштырылган Программаның тулы күләмдә чараларын гамәлгә ашыру;

- авыл җирлекләрендә яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча массакүләм чаралар системасын үстерү;

2.2. ярдәм итәргә: ;

- район акцияләрен һәм патриотик юнәлешле чараларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген күтәрүгә;

- укучылар һәм яшьләр арасында лидерларны ачыклау, аларны җәмәгать балалар һәм яшьләр оешмалары эшчәнлегенә җәлеп итү.

2.3. «Алга» газетасы һәм «Интернет» челтәрендә хәрби-патриотик берләшмәләр эшчәнлеген һәм патриотик тәрбия буенча чаралар уздыруны яктыртырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының социаль мәсьәләләр, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният һәм яшьләр эшләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов